**Татарстан Республикасы**
**Лениногорск муниципаль районы**
**Туктар-Урдаласы авыл җирлеге**
**Карагай авылында гражданнар җыены**
**КАРАРЫ**

2020 елның 20 ноябре № 4

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Туктар-Урдаласы авыл җирлегенең Карагай авылында 2022 елда үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Туктар-Урдаласы авыл җирлеге Карагай авылы гражданнары җыены КАРАР БИРДЕ:

1. 2022 елда үзара салым кертүгә Лениногорск муниципаль районы Туктар-Урдаласы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән, моннан тыш, түбәндәге категория гражданнар, ялгыз картлар һәм аз керемле гражданнар, студентлар түләүле нигездә, 500 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен юнәлдерергә:

1) Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Тельман урамында юлның вак таш җәюе;

- Карагай авылы юлларын кардан чистарту. 3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Туктар-Урдаласы авылы, Совет ур., 98 адресы буенча урнашкан административ бинада, Совет ур., 103 йорт, Карагай авылы, Тельман ур., 31 йорт адресы буенча урнашкан КФҮ бинасында урнашкан мәгълүмат стендларында, Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм

Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.r) урнаштырырга.

.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Туктар-Урдаласы авыл җирлеге башлыгы Г.Ә.Әхмәтова